**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ IV СЕССИЯСЕ**

**КАРАР № 15**

Мөслим авылы «12» декабрь 2025 ел

**2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты турында**

**1 статья**

1.2026 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 1 263 415,09 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 263 415,09 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2026 елга 0,00 мең сум күләмендә.

1. 2027 һәм 2028 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2027 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 1 372 408,50 мең сум, 2028 елга 1 485 401,52 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2027 елга 1 372 408,50 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 14 000,00 мең сум күләмендә, 2028 елга 1 485 401,52 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 28 900,00 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2027 елга 0,00 мең сум һәм 2028 елга 0,00 мең сум күләмендә.

2. 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

2.2028 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының

муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычының иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга.

3. 2029 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетында 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетына күчерелгән әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, мәҗбүри таләпләрне бозулар аркасында китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән салым булмаган керемнәр дип билгеләргә, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны ирекле түләгәндә, мәҗбүри таләпләр бозылу сәбәпле түләнә торган түләүләрдән әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауга һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыруга, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы табигатьне саклау чаралары планы нигезендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы белән килештерү буенча башка чараларга җибәрелә.

**5 статья**

1.2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2026 елга 35 832,2 мең сум, 2027 елга 37

105,3 мең сум һәм 2028 елга 38 341,8 мең сум күләмендә расларга.

**6 статья**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

2026 елга - 4 539,9 мең сум күләмендә;
2027 елга - 5 068,3 мең сум күләмендә;
2028 елга - 6 462,9 мең сум күләмендә
әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә бүленеп бирелә.

**7 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

2026 елга - 55 155,20 мең сум күләмендә;
2027 елга - 57 370,60 мең сум күләмендә;
2028 елга - 59 390,90 мең сум күләмендә
әлеге Карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә бүлү белән бәйле.

**8 статья**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга

2026 елга - 773 401,79 мең сум күләмендә;
2027 елга - 871 933,30 мең сум күләмендә;
2028 елга - 967 615,72 мең сум күләмендә
әлеге Карарның 7 нче кушымтасы нигезендә бүлү белән бәйле.

**9 статья**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2026 елга 19 293,5 мең сум, 2027 елга 19 931,9 мең сум, 2028 елга 20 234,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының гомуми кулланылыштагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга 2026, 2027 һәм 2028 елга җибәрергә.

**10 статья**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз, моңа Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирүгә бәйле рәвештә шундый карарлар кабул итү очраклары керми.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2026 елда муниципаль

хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**11 статья**

2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы исеменнән төзелгән товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә 2025 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджеты акчаларының калган өлешләре, 2026 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**12 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Мөслим районы Казначылык Департаментының территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**13 статья**

Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**14 статья**

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында https://muslumovo.tatarstan.ru/ урнаштырырга

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р. Хуҗин